# *Таҗи Гыйззәтнең тууына 125 ел*




***«Уйларым***
***һәм хисләрем***
***халык белән... »***


*Таҗи Гыйззәт*


***(1895-1955)***

***– татар әдәбияты тарихында узенең классик әсәрләре белән тирән эз калдырган һәм күренекле урын алган язучы.***

*Ул үзенең әсәрләрендә революциягә кадәрге авыл халкы тормышының авырлыгы, азатлык өчен көрәшкә күтәрелүе, җиңеп чыгуы турында дулкынланып һәм дулкынландырырлык итеп сөйли алган...*






*Таҗи Гыйззәтнең әсәрләренең нигезендә конкрет тарихи вакыйгалар ята.*

*Бу әсәрләр: «Наемщик», «Фәрхиназ», «Чаткылар», «Ташкыннар», «Бишбүләк».*

**Аның иҗатында кыз-егет мәхәббәтенә бәйләнешле вакыйгалар үстерелешен эченә алган әсәрләр дә бар. Мәсәлән, “Чаткылар”пьесасында авыл кулагы Сабир урта хәлле крестьян кызы Маһига өйләнергә тели, ә Маһи ярлы егете Гаязны сөя...**





*Талантлы драматург, заман таләпләренә җавап бирергә омтылып, үз әсәрләрендә чорның иң актуаль мәсьәләләрен кыю күтәргән, олы гражданлык җаваплылыгы тоеп иҗат иткән.*

Тажи Гыйззәт, утыз ел сузылган иҗатында, 37 драма әсәре яза, шуларның 33 е Татарстан һәм башка өлкәләрнең театрларында бара. 1923 елдан башлап хәзергә кадәр аның драма, комедияләре башкарылмаган бер генә театраль сезон юк.





***Әдәбият һәм сәнгатьне үстерүдәге зур хезмәтләре өчен Таҗи Гыйззәткә ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә, берничә мәртәбә орденнар белән бүләкләнә.***

Презентацияне төзүче: Иске-Юраш китапханәчесе Ахмадишина Равиля Фоатовна.

Кулланынлган чыганак: Сайланма әсәрләр: Тажи Гыйззәт. – Казан : Татар.кин. Нәшр., 2009.

Музыка: https://inkompmusic.ru/